СИШӘМБЕ
9 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 82 (5882)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат кузәту бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ЯЗГЫ АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫН ДӨРЕС ҺӘМ ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

Яз килеп житте. Республикабызның кайбер районнарында басулар кардан тәмам арынды. Кар астыннан иртәрәк чыккан урыннарда, бигрәк тә калкурак участокларда кыр эшләренә керешү өчен туфрак өлгереп житте.

Калинин районының Маркс исемендәге колхозында 6 нчы апрельдә ук бер бригада язгы сөрү эшенә керештеләр. „Тымытык" районының Тымытык авылы колхозы, Ютазы районының күп кенә колхозлары тунга сөрелгән участокларны тырмага чыктылар. Минзәлә районының „Победа" колхозы, Кызыл Армия районының күп кенә колхозлары клевер чәчәләр. Актаныш, Мөслим, һәм Азнакай районы колхозлары бүген-иртәгә кыр эшләренә керешү алдында торалар.

Совет хөкүмәтенең тышкы политикада ирешкән соңгы гаять зур уңышлары белән, „Авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр" турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карары белән көчле рәвештә рухланган колхозчы крестьяннәр быел авыл хуҗалыгында яңа уңышларга ирешү өчен жидди көрәш җәелдерәләр, язгы чәчүне иң кыска срокта, отлично билгесенә башкару өчен, гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алу өчен социалистик ярышны тагын да көчәйтәләр.

Язгы чәчүне иң кыска срокта үткәрү белән бергә һәрбер колхозда, һәрбер бригадада һәм һәрбер звенода язгы агротехника чараларының дөрес һәм тулысынча үтәлүенә аеруча игтибар бирергә кирәк. Барыннан да элек, чәчү орлыкларының сыйфатына нык әһәмият бирергә кирәк.

Язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча дәвам итә торган эшче-авыл хәбәрчеләре рейде Татарстанның күп кенә колхозларында чәчү орлыкларының тиешле кондициядә түгеллеген, ягни яңадан тазартмый торып һәм триер аркылы үткәрми торып чәчәргә яраксыз булуын күрсәтә. Мәсәлән, Куйбышев районында тикшерелгән 20.637 центнер орлыкның 7.065 центнеры, Кызыл Армия районында тикшерелгән 13.088 центнер орлыкның 3.878 центнеры чүпле.

Социалистик авыл хуҗалыгы шартларында чәчү орлыкларының чүпсез булуы гына житми. Орлык агуланырга да һәм яровойлаштырылырга да тиеш. Бу— мәҗбүри рәвештә үткәрелергә тиешле чара. Кызганычка каршы, аерым районнарда бу тармакта үткән елгы кимчелекләрне кабатлауга, агуланмаган орлык чәчәргә, димәк, иген уңышын киметүгә хәзердән үк юл куялар. Ширәмәт һәм Октябрь районнарында орлык агулау материалларының көздән үк житәрлек күләмдә хәзерләнүенә дә карамастан, хәзергә кадәр бер генә центнер орлык та коры юл белән агуланмаган. Ә Тельман районында (җир бүлеге мөдире Тукманов, баш агроном Янилькин иптәшләр) орлык агулау материалларын колхозларга кайтарту чараларын да күрмиләр.

1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләренең дәүләт планын яхшы үтәү өчен Татарстан АССР, Чувашстан АССР һәм Мордовия АССР арасында төзелгән социалистик ярыш договоры буенча без быел яз көне бөртекле культураларны 600 мең гектар мәйданга һәм бәрәңгене 15 мең гектар мәйданга яровойлаштырып чәчәргә йөкләмә алды. Урыннардагы фактлар исә иген уңышын күтәрүдә берничә еллар сынаган һәм гаять яхшы нәтиҗәләр биргән бу агротехника чарасының әле үтәлми калу куркынычы барлыгын күрсәтәләр. Безнең Татарстан АССР шартларында бәрәңгене яровойлаштыруга салу 1 нче апрельдән дә соңга калмый тәмамланырга тиеш. Ә менә Октябрь районында күп кенә колхоз да яровойлаштыруны бер генә гектарда да башламаган. Яровойлаштыру өчен бина хәзерләнмәгән. Ширәмәт районында да шундый ук хәл.

Кайбер колхозларда ужымнар [illegible] калдылар. Андый ужымнар яз көне өстән тукландыруга мохтаҗ булалар. Яңа Чишмә районының күп колхозлары өчен мондый чараның үткәрелүе бигрәк тә кирәк. Задание буенча Яңа Чишмә районында 770 гектар мәйданда ужым тукландыру үткәрелергә тиеш. Ләкин район җир бүлеге бу заданиене колхозларга җиткерү белән мәсьәлә хәл ителде дип уйлаган, күрәсең. Чөнки анда ужым тукландыру өчен кирәкле база хәзерләүне оештырмаганнар. Районда кош тизәге хәзерләү планы бары 55 процент, көл хәзерләү планы бары 43 процент үтәлгән. План буенча хәзерләнергә тиешле 600 тонна урынына бары 60 тонна сыекча хәзерләнгән.

Кыр эшләренә керешкән районнарда да ужымнарны тукландыру эшен онталар. Тукландыру өчен иртә туң вакыттан файдалану бер генә районда да оештырылганы юк.

Әле соң түгел. Ужым тукландыру өчен барлык мөмкинлекләрне тупларга кирәк. Тукландыру өчен иртә туңнан файдаланырга, тукландыру планнарының арттырып үтәлүенә ирешергә кирәк.

Туңга сөрелгән җирләрне яз көне эшләү мәсьәләсе дә аеруча әһәмиятле чаралардан санала. Туңга сөрү бездә киң күләмдә үткәрелә торган агрономия чарасы ул. Ләкин күп кенә колхозларда, бигрәк тә республикабызның төньяк районнарындагы колхозларда, туңга сөрелгән җирләрне яз көне яңадан сөрү тенденциясе бар. Бу, һич шиксез, ялгыш һәм искергән караш. Туңга сөрелгән җирне яз көне тырмалау һәм культивацияләү урнына аны яңадан сөрү бик күңелсез нәтиҗәгә китерергә мөмкин. Ул туфракта көз, кыш һәм яз көннәрендә тупланган дымны һавага очырып бетерүгә сәбәп була. Агрономнар, агротехниклар бу турыда үзләренең кискен сүзләрен тагын бер кат әйтергә, колхозчыларга яхшылап һәм тәмам ышандырырлык итеп, конкрет фактлар белән аңлатырга тиешләр. Туңга сөрелгән җирләрне яңадан сөрүгә тик аерым хәлләрдә генә юл куелырга тиеш.

Язгы чәчүнең иң кыска срокта үтәлүен тәэмин итү белән бер рәттән, югарыда күрсәтелгән бу чараларның бөтенесенең дә дөрес итеп һәм тулысынча үтәлүенә ирешергә кирәк. Һәм бу, һич шиксез, шулай булыр. Татарстан АССР колхозлары һәм совхозлары социалистик ярыш буенча үз өсләренә алган йөкләмәне намус белән үтәрләр.

Эшкә, язгы чәчүне кыска срокта һәм югары сыйфат белән үтәүгә!

ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ

БАУЛЫ, 8 апрель. **(Телефон буенча)** „Победа" колхозы туңга сөрелгән җирләрне тырмалау эшенә керешге. Районның „Революция", Урал, Ленин һәм Куйбышев исемендәге колхозлары да бүген тырмага чыгалар.

Шушы көннәрдә районның күпчелек колхозларында массовый төстә кыр эшләре башланачак.

Агроном *Рәхимов.*

***

ПУЧЫ, 8 апрель. **(Телефон буенча).** Калинин районының байтак колхозларында туңга сөргән җирләрне тырмалау һәм язгы сөрү эшләре башланды.

„Ташьелга" колхозы 50 гектар, „Лена" колхозы 30 гектар, Киров исемендәге колхоз 10 гектар җир тырмаладылар. Маркс исемендәге колхоз 30 гектар, „Удар" колхозы 10 гектар, „Октябрь" колхозы 10 гектар җир сөрделәр инде.

Герасимов.

***

ТЫМЫТЫК. **(Телефон буенча).** Басулар кардан чистарып бетте. Колхозлар бүген-иртәгә масса күләмендә язгы кыр эшләренә керешү алдында торалар. 5 нче апрельдә Тымытык авылы колхозы туңга сөрелгән җирләрне тырмалау эшенә кереште.

Гайнанов.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР ҺӘМ РЯДОВОЙЛАР СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ДИГӘН ИСЕМНЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул ук вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Советлар Союзы Герое** исме, **Ленин** ордены һәм **„Алтын Йолдыз"** медале бирергә:

1. Кече лейтенант Григорий Михайлович **Айрипетьянга.**
2. Кече лейтенант Семен Павлович **Альпеевкә.**
3. Лейтенант Александр Иванович **Андрияновка.**
4. Кече командир Бронислав Романович **Антилевскийга.**
5. Кече командир Гафиль Шаһиманнур улы **Арслановка.**
6. Кызыл армеец Иван Тимофеевич **Артемовка.**
7. Майор Иван Филиппович **Балашовка.**
8. Кече лейтенант Михаил Иванович **Бекетовка.**
9. Кече политрук Петр Устинович **Богатырьга.**
10. Өлкән политрук Василий Романович **Бойкога.**
11. Кызыл армеец Иван Никитович **Бойцовка.**
12. Кече командир Сергей Николаевич **Бутяковка.**
13. Лейтенант Михаил Иванович **Быковка.**
14. Өлкән лейтенант Гавриил Тарасович **Василенкога.**
15. Капитан Леонид Васильевич **Виноградовка.**
16. Кызыл армеец Борис Алексеевич **Винокуровка.**
17. Политрук Николай Поликарпович **Власинкога.**
18. Капитан Петр Алексеевич **Вовнага.**
19. Кызыл армеец Николай Семенович **Грековка.**
20. Лейтенант Михаил Александрович **Гуденкога.**
21. Кече командир Георгий Данилович **Гуслевка.**
22. Политрук Василий Леонтьевич **Гутинга.**
23. Кызыл армеец Александр Самуилович **Демкинга.**
24. Лейтенант Леонид Ильич **Дуберга.**
25. Өлкән лейтенант Михаил Тарасович **Дударенкога.**
26. Лейтенант Спиридон Михайлович **Егоровка.**
27. Лейтенант Стефан Ефимович **Елейниковка.**
28. Кызыл армеец Виктор Алексеевич **Емельяновка.**
29. Майор Иван Петрович **Журавлевка.**
30. Майор Виктор Владимирович **Зеленцовка.**
31. Кече командир Андрей Филиппович **Зининга.**
32. Кызыл армеец Федор Иванович **Ивановка.**
33. Кече командир Александр Александрович **Игашовка.**
34. Шофер Иван Михайлович **Ильиныхка.**
35. Өлкән лейтенант Казбек Дрисович **Карсановка.**
36. Кече командир Константин Андреевич **Каськовка.**
37. Политрук урынбасары Алексей **Кивага.**
38. Полковник Василий Ильич **Клевцовка.**
39. Лейтенант Илья Иванович **Климовка.**
40. Шофер Василий Степанович **Клюкинга.**
41. Кече командир Николай Павлович **Кожановка.**
42. Кече лейтенант Ефим Михайлович **Козловка.**
43. Лейтенант Анатолий Филиппович **Коломейцевка.**
44. Лейтенант Николай Николаевич **Комаровка.**
45. Лейтенант Константин Иванович **Кораблевка.**
46. Кече политрук Петр Семенович **Костровка.**
47. Кече командир Борис Львович **Кузнецовка.**
48. Кече командир Константин Григорьевич **Кузнецовка.**
49. Өлкән лейтенант Петр Федорович **Куксовка.**
50. Өлкән лейтенант Павел Иванович **Кулейкинга.**
51. Өлкән политрук Виктор Дмитриевич **Кучерявыйга.**
52. Лейтенант Александр Фадеевич **Кшенскийга.**
53. Механик-водитель Федор Иванович **Ламзинга.**
54. Өлкән политрук Андрей Ефимович **Левочкинга.**
55. Полковник Дмитрий Данилович **Лелюшенкога.**
56. Капитан Николай Константинович **Леонченкога.**
57. Кызыл армеец Федор Акимович **Липаткинга.**
58. Кызыл армеец Василий Иванович **Лихачевка.**
59. Кызыл армеец Иван Петрович **Лякинга.**
60. Капитан Сахип Нуролгаян улы **Майскийга.**
61. Кызыл армеец Иосиф Маркович **Максименяга.**
62. Кече командир Ивак Маркосович **Манасянга.**
63. Кече лейтенант Александр Маркович **Марковка.**
64. Кече лейтенант Виктор Григорьевич **Масичка.**
65. Кече командир Николай Ефимович **Матвиенкога.**
66. Кызыл армеец Клим Григорьевич **Матузовка.**
67. Механик-водитель Николай Васильевич **Машковка.**
68. Өлкән лейтенант Сергей Иванович **Мироновка.**
69. Кызыл армеец Василий Сергеевич **Мичуринга.**
70. Майор Семен Иванович **Младенцевка.**
71. Лейтенант Владимир Афанасьевич **Назаренкога.**
72. Капитан Василий Гаврилович **Нетревка.**
73. Кече командир Василий Григорьевич **Нечаевка.**
74. Кече лейтенант Григорий Евсеевич **Никитенкога.**
75. Политрук Василий Федорович **Овчинниковка.**
76. Кече командир Павел Романович **Олейниковка.**
77. Капитан Константин Николаевич **Орловка.**
78. Өлкән политрук Артем Спиридонович **Пасечникка.**
79. Капитан Петр Михайлович **Петровка.**
80. Политрук урынбасары Иван Андреевич **Петрушинга.**
81. Өлкән лейтенант Владимир Васильевич **Письменныйга.**
82. Өлкән лейтенант Иван Тимофеевич **Петровка.**
83. Лейтенант Степан Иванович **Полянскийга.**
84. Политрук Александр Васильевич **Прохоровка.**
85. Өлкән лейтенант Иван Иванович **Прошинга.**
86. Полковник Иван Гаврилович **Пятыхинга.**
87. Кече лейтенант Василий Петрович **Розановка.**
88. Кече командир Александр Михайлович **Романенковка.**
89. Кече командир Андрей Михайлович **Серебряковка.**
90. Өлкән лейтенант Николай Петрович **Сенютинга.**
91. Механик-водитель Иван Данилович **Сиволапка.**
92. Кече лейтенант Анатолий Петрович **Сироткинга.**
93. Кече командир Андрей Васильевич **Ситькога.**
94. Лейтенант Александр Иванович **Словновка.**
95. Кызыл армеец Александр Федорович **Стеблевка.**
96. Лейтенант Николай Максимович **Стольниковка.**
97. Өлкән лейтенант Дмитрий Евгеньевич **Строгановка.**
98. Механик-водитель Василий Васильевич **Стрючковка.**
99. Лейтенант Лука Федорович **Тарасовка.**
100. Өлкән лейтенант Андрей Григорьевич **Телешевка.**
101. Лейтенант Николай Павлович **Толмачевка.**
102. Кече командир Петр Егорович **Толстовка.**
103. Полковник Дмитрий Иванович **Турбинга.**
104. Лейтенант Николай Федорович **Турцевичка.**
105. Кече лейтенант Михаил Петрович **Тюринга.**
106. Кече командир Иван Никитич **Ударовка.**
107. Лейтенант Василий Федорович **Федоровка.**
108. Капитан Евгений Петрович **Федоровка.**
109. Кече командир Павел Степанович **Федорчукка.**
110. Кызыл армеец Федор Алексеевич **Харитоновка.**
111. Лейтенант Иван Степанович **Худяковка.**
112. Политрук Михаил Васильевич **Черниковка.**
113. Кече командир Александр Кондратьевич **Чернышевка.**
114. Комбриг Степан Иванович **Чернякка.**
115. Өлкән лейтенант Демид Яковлевич **Шевенокка.**
116. Лейтенант Николай Федорович **Шемелевка.**
117. Өлкән лейтенант Федор Иванович **Шинкаренкога.**
118. Батальонный комиссар Леонтий Игнатьевич **Яковенкога.**
119. Политрук Иван Федорович **Якушенкога.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 7 апрель, 1940 ел.

„Доброволецлар" ның настроениесе турында Швеция язучысы

СТОКҺОЛЬМ, 7 апрель. (ТАСС). Швеция „доброволецлары" ачы өметсезләнү хисе белән үзләренең илләренә кайталар. Алар үзләрен өметсез һәм җүләрләрчә эшкә этәргән „активистлар" ның һәм буржуаз матбугатның алдауларына һәм аларга дошманнарча караган финнәргә ачуланалар. Швеция язучысы Норд провинциал социал-демократлар газетасы „Вестманландс фолькблад" та болай дип яза: „Шведлар хәзер Финляндиядән төрле хисләр белән кайталар. Солых төзелгәннән соң Ботника заливының теге ягында швед булу бик кызыклы түгел иде. Нининдидер коточкыч хәл булды һәм мондый хәлдә төрле вакыйга булырга мөмкин иде. Таннерның 13 нче мартта радиодан сөйләгән речe финнәрнең безгә, шведларга каршы дошманлыгы көчәюгә нык тәэсир итте. Бу речендә Таннер фин халкын „Швециянең һәм Норвегиянең Финляндияне иң хурлыклы төстә сатканлыкларына" ышандырды һәм әгәр көнбатыш державаларның Финляндиягә ярдәм итәргә мөмкинлекләре булса аның коткарылган булачагына" ышандырды. Таннерның речена караганда, без, шведлар, кызганыч хиянәтчеләр төркеме булганбыз, швед доброволецлары Финляндиягә фин икмәген ашар өчен генә килгәннәр һәм без күрсәткән аз гына ярдәм (400 миллион крон)—безнең намуссызлыгыбызның нәтиҗәсе генә имеш. Таннер Швециянең ярдәменнән көлде: „Швеция һәрбер солдатка 7 пар җылы наколенник бәйли! Тиздән безнең егетләрне кояштан саклау өчен салам шляпалар да килеп җитәр инде".

Аннары бер фин офицерының алдынгы позицияләрдә эшләүче бер швед врачын нык мәсхәрә итүе турында сөйләп, автор болай ди: „Без килештерү сүзләрен чиркәүдә генә булса да ишетергә теләп чиркәүгә бардык. Ләкин аның урнына без попның: „Мин швед булмавыма аллага шөкрана кылам" дигән тавышын ишеттек".

Аннары Норд шагыйрь Лагеркранцның язуларын мисальгә китерә. Бу шагыйрь Финляндиядә Швеция телеграф агентлыгының хәбәрчесе булган һәм ялганлавы белән аеруча аерылып торган. Бу хәбәрченең аеруча ялган хәбәрләрен мисальгә алып, автор болай ди: „Моны бер кайчан да дары иснәмәгән кеше язган. Ләкин мондый хәл бик киң күләмдә күренде, һәр кемнән дә азрак эшләүчеләр башкалардан күбрәк кычкырдылар. Фронтовиклар кычкырмадылар. Мин солых төзелгәннән соң берничә көнгә ял алган офицерлар һәм солдатлар белән сөйләштем. Алар моның хәзер алырга мөмкин булган иң яхшы солых икәнлеген әйттеләр. Вагдә ителгән барлык ярдәмнәргә карамастан, сугышны дәвам иттерүнең Финляндиянең җимерелүенә китерәчәген алар белделәр. Әгәр тылдагы кешеләр чынлыкны солдатлар аңлаганча аңласалар иде, күп нәрсә булмаган булыр иде". Норд финнәр белән Финляндиядә яшәүче шведлар арасындагы элекке бәхәсләрнең яңа көч белән кабынып киткәнлеген һәм хәзер күп кенә шведларның Финляндиядән китәргә теләүләрен яза.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ГАСКӘРИ ЧАСТЬЛӘРЕН ҺӘМ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕН СССР ОРДЕННАРЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен бүләкләргә:

ЛЕНИН ОРДЕНЫ БЕЛӘН

136 нчы укчы дивизияне
39 нчы аерым җиңел танк бригадасын

КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ ОРДЕНЫ БЕЛӘН

17 нче моторлаштырылган укчы дивизияне
49 нчы укчы дивизияне
90 нчы укчы дивизияне
40 нчы аерым җиңел танк бригадасын
69 нчы укчы полкны
271 нче моторлаштырылган укчы полкны
306 нчы укчы полкны
359 нчы укчы полкны
43 нче корпус авыр артиллериясе полкын
49 нчы корпус авыр артиллериясе полкын
101 нче гаубица артиллериясе полкын
116 нчы гаубица артиллериясе полкын
137 нче гаубица артиллериясе полкын
202 нче артиллерия полкын
291 нче җиңел артиллерия полкын
311 нче пушка артиллериясе полкын
334 нче артиллерия полкын
455 нче корпус артиллериясе полкын
227 нче аерым сапера батальонын
4 нче аерым элемтә батальонын
6 нчы аерым понтон-күпер батальонын

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

„На страже родины" газетасын Кызыл Байрак ордены белән бүләкләү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында Кызыл Армия частьләрен политик яктан тәрбияләү һәм дисциплинаны ныгыту эшендәге күренекле хезмәтләре өчен „На страже родины" газетасын Кызыл Байрак ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 апрель, 1940 ел.

ХРОНИКА

СССР Верховный Советы Президиумы иптәш И. С. Зотовны ССР Союзының Финляндиядәге тулы хокуклы илчесе итеп билгеләде.

***

Финляндия хөкүмәте Финляндиянең СССР дагы илчесе итеп Ю. К. Паасикиви әфәндене билгеләве турында ризалык сорады. ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Ю. К Паасикиви әфәнде өчен үзенең ризалыгын бирде.

***

СССР Верховный Советы Президиумы иптәш В. К. Деревянскийны ССР Союзының Латвиядәге тулы хокуклы илчесе итеп билгеләде.

***

ССР Союзы Совнаркомы иптәш **Н. Е. Скорняковны** СССР ның Балык Промышленносте халык комиссарының урынбасары итеп билгеләде.

***

ССР Союзы Верховный Советы Президиумы 1940 нчы елның 7 нче апрелендә Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Иран арасында сәүдә һәм диңгез юлы турында 1940 нчы елның 25 нче мартында Таһран шәһәрендә төзелгән договорны ратификацияләде.

СССР ның I нче ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ТАРАФЫННАН КАБУЛ ИТЕЛГӘН ЗАКОННАР

ДОХОД НАЛОГЫ САЛЫНА ТОРГАН ХАЛЫКТАН ТОРАК ҺӘМ КУЛЬТУРА-КӨНКҮРЕШ ТӨЗЕЛЕШЕ КИРӘКЛӘРЕНӘ ҖЫЕМ ТУРЫНДА ЗАКОН

Статья 1. Торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыемны эшчеләр, хезмәткәрләр, әдәбият һәм сәнгат работниклары, кустарьлар, һөнәрчеләр һәм доход налогы салына торган аерым доходлары булган башка гражданнар түлиләр.

Статья 2. Җыем доход налогы исәпләгәндә билгеләнгән доходтан алына.

Статья 3. Доход налогы турындагы законда күздә тотылган льготалар торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем алганда да кулланыла.

Статья 4. Эшчеләрдән, хезмәткәрләрдән һәм доход налогы салу буенча шулар белән бер дәрәҗәдәге башка гражданнардан җыем аларның үткән айдагы хезмәт хакларыннан исәпләнә һәм шушы айның беренче яртысы хезмәт хакыннан түбәндәге күләмнәрдә тотып калына:

Айлык хезмәт хакы күләме	Җыем сумасы
151 сумнан 200 сумга кадәр	1 с. 05 т. һәм 150 сумнан арткан сумадан 2,5%
201 „ 300 „ „	2 с. 30 т. „ 200 „ „ „ 3,0%
301 „ 500 „ „	5 с. 30 т. „ 300 „ „ „ 3,5%
501 „ 700 „ „	12 с. 30 т. „ 500 „ „ „ 4,5%
701 „ 1.000 „ „	21 с. 30 т. „ 700 „ „ „ 5,5%
1.001 сум һәм артыграк	37 с. 80 т. „ 1.000 „ „ „ 6%

Искәрмә: Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең бер үк вакытта башкарыла торган эшләренен (төп эш урнында булмаса) һәм вакытлы эшләрне башкарудан булган хезмәт хакларыннан җыем һәрбер эш урны буенча аерым рәвештә исәпләнә. Бу хезмәт хаклары өчен налог салынмый торган минимум (халыктан доход налогы турындагы законның 2 нче статьясе) кулланылмый һәм аена 150 сумга кадәр булган хезмәт хакыннан җыем айлык хезмәт хакы сумасының 0,7 проценты күләмендә исәпләнә.

Статья 5. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр белән бер үк нигезләрдә, ләкин җыем сумасын 10 процент артык итеп түбәндәгеләр түлиләр:

а) кооперативлаштырылган кустарьлар һәм артельләрнең гомуми мастерскойларында эшләүче һөнәрчеләр;

б) транспорт промысло-кооператив артельләренең членнары (эш терлекләре җәмагатьләштерелгән булса);

в) кооперативлаштырылган кустарьлар һәм һөнәрчеләр, шулай ук өйләрендә эшләгәннәре өчен артельләрдән һәм предприятиеләрдән ала торган хезмәт хаклары буенча эшчеләр һәм хезмәткәрләр—әгәр алар аерым гражданнар өчен эшләмәсәләр, промыслода үз материалларын кулланмасалар һәм үз эшләрендә махсус җиһазлардан (тегү машиналарыннан тыш машиналардан, станоклардан һ. б.) файдаланмасалар.

Статья 6. Әдәбият һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларыннан җыем доход налогы белән бер үк вакытта түбәндәге күләмнәрдә алына:

Еллык доход күләме	Җыем сумасы
1800 сумга кадәр	Доход сумасыннан 0,7%
1.801 сумнан 2.400 „ „	12 с. 60 т. һәм 1.800 сумнан арткан сумадан 2,5%
2.401 „ 3.600 „ „	27 с. 60 т. „ 2.400 „ „ „ 3,0%
3.601 „ 6.000 „ „	63 с. 60 т. „ 3.600 „ „ „ 3,5%
6.001 „ 8.400 „ „	147 с. 60 т. „ 6.000 „ „ „ 4,5%
8.401 „ 12.000 „ „	255 с. 60 т. „ 8.400 „ „ „ 5,5%
12.001 „ сум һәм артыграк	453 с. 60 т. „ 12.000 „ „ „ 6,0%

Статья 7. Кооперативлаштырылмаган кустарьчылык-һөнәрчелек промыслоларыннан, корылышлардан, шәһәрләрдәге һәм эшчеләр поселкыларындагы авыл хуҗалыгыннан булган доходлардан һәм 4, 5 һәм 6 нчы статьялардәге тәртиптә налог салына торган доходлардан тыш башка доходлардан җыем түбәндәге күләмнәрдә алына:

Еллык доход күләме	Җыем сумасы
1.200 сумга кадәр	Доход сумасыннан 2,5%
1.201 сумнан 2.400 „ „	30 с. һәм 1.200 сумнан арткан сумадан 4,0%
2.401 „ 4.800 „ „	78 с. „ 2.400 „ „ „ 6,0%
4.801 „ 10.000 „ „	222 с. „ 4.800 „ „ „ 7,5%
10.001 сум һәм артыграк	612 с. „ 10.000 „ „ „ 8,0%

Статья 8. Үз материалларыннан әйберләр эшләүче кооперативлаштырылмаган кустарьларның һәм кооперативлаштырылмаган извозчикларның доходларыннан 7 нче статья тәртибендә исәпләнә торган җыем сумасы 35 процентка арта, ә дин хезмәткәрләре өчен һәм хезмәт доходлары булмаган башка кешеләр өчен 40 процентка арта.

Статья 9. Врачларның, фельдшерларның, адвокатларның, укытучыларның һәм башка кешеләрнең частный практика хезмәт хаклары буенча, әгәр алар елына 10.000 сумнан артмаса, шушы законның 7 нче статьясе буенча исәпләнә торган җыем сумасы 25 процентка кимителә.

Статья 10. Извозчикларга хезмәт хакы түләгәндә предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар түләнә торган хезмәт хакы сумасыннан җыем исәбенә 5 процент тотып калырга тиешләр.

Статья 11. Кооперативлаштырылмаган кустарьлар, һөнәрчеләр һәм 4, 5 һәм 6 нчы статьялар тәртибендә җыем салына торган гражданнардан башкалар җыемны тигез өлешләргә бүлеп 4 срокта түлиләр: 5 нче мартта, 5 нче майда, 5 нче августта һәм 5 нче ноябрьдә.

Статья 12. Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан тотып калынган җыем сумасын банк учреждениеләренә күчерү, шулай ук эшчеләр һәм хезмәткәрләр тотучы районның финанс бүлекләренә отчетлар бирү доход налогы турындагы закон белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Җыем турындагы законны бозган өчен җәза бирү дә шул ук тәртиптә үткәрелә.

Статья 13. Җыемны билгеләнгән срокларда түләмәгән хәлләрдә недоимщикларга карата доход налогы турындагы закон белән күздә тотылган чаралар кулланыла.

Статья 14. Бу законны куллану буенча инструкциене СССР Финанс Халык Комиссариаты чыгара.

Статья 15. Бу закон 1940 нчы елның 1 нче январеннан гамәлгә кертелә, ә бу закон нигезендә эшчеләрдән һәм хезмәткәрләрдән (һәм шулар белән бер дәрәҗәдәге түләүчеләрдән) җыемны беренче тапкыр тоту 1940 нчы елның июнь аеның «беренче яртысы хезмәт хакыннан үткәрелә.

Статья 16. Украина ССР ның Волынь, Дрогобыч, Львов, Ровно, Станислав һәм Тарнополь өлкәләрендә һәм Белоруссия ССР ның Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка һәм Пинск өлкәләрендә эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакларыннан, әдәбият һәм сәнгат работникларының хезмәт хакларыннан, шулай ук врачларның, фельдшерларның һәм адвокатларның частный практика доходларыннан җыем шушы закон нигезендә алына.

Бу өлкәләрдә гражданнарның башка чыганаклардан булган доходларыннан җыем СССР Совнаркомының 1940 нчы ел 19 нчы мартта чыгарылган 370 нче номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә алына.

Статья 17. Шушы закон гамәлгә кертелү белән түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип санарга:

а) «Шәһәрләрдә һәм авыл җирләрендә торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турында» СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Совнаркомының 1934 нче ел, 23 нче январь карарының 1 нче статьясенең „а" пунктын, 2—4, 7, 8, 12—17 һәм 19—25 нче статьяларын (СССР Законнар Җыентыгы, 1934 ел, номер 5, ст. 38; 1935 ел, №22, ст. 170; 1936 ел, №2, ст. 18); СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Совнаркомының 1934 нче ел, 23 нче январь карарының 18 нче статьясенең колхоз членнары булмаган шәһәрләрдә, эшчеләр поселкыларында авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә карата булган өлеше белән законнар (СССР Законнар Җыентыгы, 1937 ел, №19, ст 72);

б) „1935 нче елга шәһәрләрдә һәм авыл җирләрендә торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турында" СССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Совнаркомының 1935 нче ел, 14 нче январь карарының 1 нче статьясе (СССР Законнар Җыентыгы, 1935 ел, №4, ст. 31).

Статья 18. Союзный республикаларның халык комиссарлары советларына, — республикаларның законнарына шушы законга туры китерел үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 4 апрель, 1940 ел.

Мәҗбүри окладной страхование турында закон

I. Нинди милек страховать ителергә тиеш

1. Колхозларда мәҗбүри окладной страхованиегә түбәндәгеләр тартыла:

а) төзелешләр, инвентарь, җиһазлар, транспорт средстволары, продукция, чимал һәм материаллар;

б) авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре (шул исәптән рассадникларда, парникларда һәм теплицаларда булганнары да), питомниклар һәм бакчаларның, җиләклекләрнең һәм виноградлыкларның уңышы;

в) 6 айлыктан зур булган мөгезле эре терлекләр, сарыклар, кәҗәләр һәм дуңгызлар; 1 яштән зур булган атлар, дөяләр, ишәкләр, качырлар һәм боланнар, ә яхшы нәселле яш атларның, дөяләрнең һәм ишәкләрнең 6 айлыктан узганнары;

г) балык тоту суднолары.

2. Гражданнарның хуҗалыкларында шәхси милек хокукында булган түбәндәге милекләр мәҗбүри окладной страхованиегә тартылалар:

а) корылмалар;

б) 6 айлыктан узган мөгезле эре терлекләр; 1 яштән узган атлар, дөяләр, ишәкләр, качырлар, сарыклар һәм кәҗәләр; 9 айлыктан узган дуңгызлар;

в) авыл хуҗалыгы культураларының кырдагы чәчүлекләре.

II. Зианнар нинди хәлләрдә каплана

3. Корылышларны, ә колхозларда алардан тыш инвентарьны, җиһазларны, транспорт средстволарын, продукцияне, чималны һәм материалларны страховать итү буенча Госстрах янгыннан, яшен сугудан, шартлаудан (яшен сугу яки шартлау янгын китереп чыгармасалар да), су басудан, җир тетрәүдән, давылдан, ураганнардан, көчле яңгырлардан, боз сугудан, тау җимерелүдән һәм җир шуышудан килгән зианнарны каплый.

Госстрах страховать итүчеләргә әгәр янгынның җәелүен туктату өчен яки кинәт су басу куркынычы туганда корылышны сүтәргә, яки икенче урынга күчерергә туры килгән хәлләрдә дә зианны түли.

4. Авыл хуҗалыгы культураларын страховать итү буенча Госстрах түбәндәге төр зианнарны түли:

а) боз сугудан, көчле яңгырдан, давылдан һәм игеннең үскән вакытта януыннан;

б) чыланудан, өшүдән, черүдән, туңудан һәм су басудан.

5. Мамык, кунжут, клещевина, змееголовник, фенхел, сафлор, кориандр, арахис, тәмәке, махорка, анис, соя, дөге, кенаф, канатник, герань, белладонна, валериана, камфаралы базилик, люфа, кара мальва, наперстянка, мята, шалфей, тмин, далматия ромашкасы, перилла, рами, ворсоваль шишка, каучуклы культуралар чәчүлекләрен, шулай ук колмак һәм Казанлык розасын страхованиеләү буенча, боз сугудан, көчле яңгырлардан, давыллардан, үскәндә янудан, дымланып черүдән, өшүдән, бозылудан, салкыннардан, су басудан һәм корылыктан килгән зарарлар түләнәләр.

6. Терлекләрне страхованиеләү буенча Госстрах авыру, картаю һәм бәхетсезлек вакыйгасе нәтиҗәсендә үлгән хәйваннар өчен тиешле сумаларны түли.

Шулай ук суярга мәҗбүр булган хәйваннар өчен Госстрах тиешле суманы түли:

а) әгәр дә терлек йогышлы авыруларга каршы көрәш чаралары үткәрелү уңае белән ветеринария врачы яки ветеринария фельдшеры бойрыгы белән суелса;

б) әгәр дә терлек бәхетсезлек вакыйгасенә очраса һәм аңа котылгысыз һәлакәт куркынычы туса һәм ветеринария врачының, ветеринария фельдшерының, ә алар булмаганда авыл советы депутатының бойрыгы белән суелган булса;

в) әгәр дә терлек анардан моннан соң файдаланырга мөмкинлек бирмәслек төзәлмәслек авыру белән авырып, аны суярга ветеринария врачы яки ветеринария фельдшеры бойрык биргән булса.

7. Балык тоту судноларын страхованиеләү буенча Госстрах түбәндәгеләрдән килеп чыккан зарарларны түли:

а) янгыннан, яшен сугудан, давылдан, ураганнан, өермәдән, штормнан;

б) яр буена, скалага, су астындагы ташларга һәм һәр төрле хәрәкәтсез яки йөзеп йөри торган әйберләргә бәрелүдән,—әгәр дә бу бәрелү давыл, ураган, өермә, шторм яки томан аркасында килеп чыкса;

в) давыл, ураган, өермә, шторм яки томан вактында судноның комга утыруыннан;

г) моторның яки пар казаннарының шартлавыннан;

д) йөзү вактында яки СССР Наркомфлоты яисә СССР ның Наркомречфлоты органнары тарафыннан кышлау өчен куркынычсыз дип табылган урыннарда торган вакытта судноларның боз белән зарарлануыннан;

е) давыл, ураган, өермә яки шторм аркасында судноның хәбәрсез югалуыннан.

8. Милекне 3, 4, 5 һәм 6 нчы статьяләрдә саналган табигый бәләләрдән мәҗбүри рәвештә окладной страхованиеләү (1 һәм 2 нче статьялар) һәммә җирдә дә үткәрелә.

Балык тоту судноларын 7 нче статьядә саналган табигый бәләләрдән страхованиеләү барлык диңгезләрдә һәм түбәндә күрсәтелгән күлләрдә үткәрелә: Ладога, Онега, Ак, Чуд (Елы күл белән), Псков, Балхаш, Байкал, Ильмен, Палеостома һәм Иссык-Күл күлләрендә.

Союзный республикаларның халык комиссарлары советларына, Госстрах белән килешү буенча, балык тоту судноларын страхованиеләү тәртибен балык тоту промыслолары булган башка суларда да кулланырга хокук бирергә.

III. Страхование акчасы нинди сумада түләнә

9. Әгәр дә колхозлар карамагындагы корылышлар, инвентарь, җиһазлар, транспорт средстволары, продукция, чимал, материаллар, шулай ук балык тоту суднолары (ст. 7) уттан һәм башка төрле табигый бәләләрдән һәлак булсалар (ст. 3) страхование акчасы инвентарь бәясе буенча милекнең тулы бәясе күләмендә, ә үзләре өчен файдалану хокукы белән гражданнар кулында булган корылышлар өчен страхование бәясе буенча корылышларның тулы бәясе күләмендә түләнә (шәһәр җирләрендә—коммуналь хуҗалык халык комиссариатлары органнары билгели торган бәя буенча).

10. Әгәр дә авыл хуҗалыгы культуралары һәлак булса страхование акчасы түбәндәге нормалар буенча түләнә (1 гектарга сумнар белән):

Республикалар.	Хуҗалык категорияләре.	Бөртекле; кузаклы культуралар, кудряш җитен, көнбагыш, чәчелгән үләннәр (орлык өчен чәчелгәннәреннән башкалары), силос культуралары, горчица, кунжут, клещевино, фенхель, анис, соя, кенаф, канатник, сафлор һәм кориандр.	Яшелчә культуралары һәм бу культураларның орлыклыклары, бакча культуралары.	Бакчалар (шул исәптән цитрус үсемлекләр), җиләклекләр.	Виноград бакчалары.	Мамык.	Сары тәмәке һәм сигара тәмәкесе.
1	2	3	4	5	6	7	8
РСФСР	Колхозларга	60	500	700	1.000	200	1.200
	Ялгыз хуҗалыкларга .	50	400	—	—	160	1.000
УССР	Колхозларга	70	500	800	900	200	800
	Ялгыз хуҗалыкларга .	60	400	—	—	160	650
БССР	Колхозларга	60	500	700	—	—	800
	Ялгыз хуҗалыкларга .	50	400	—	—	—	650
Азербәйҗан ССР	Колхозларга	80	800	1.000	1.500	400	1.400
	Ялгыз хуҗалыкларга .	60	650	—	—	300	1.100
Грузия ССР	Колхозларга	80	800	1.000	1.500	400	1.600
	Ялгыз хуҗалыкларга .	60	650	—	—	300	1.300
Әрмәнстан ССР	Колхозларга	90	800	1.000	1.500	400	1.300
	Ялгыз хуҗалыкларга .	70	650	—	—	300	1.000
Төркмәнстан ССР	Колхозларга	75	900	1.200	1.500	500	700
	Ялгыз хуҗалыкларга .	55	800	—	—	400	550
Үзбәкстан ССР	Колхозларга	75	900	1.200	1.500	600	1.000
	Ялгыз хуҗалыкларга .	55	800	—	—	500	800
Таҗикстан ССР	Колхозларга	75	900	1.200	1.500	500	700
	Ялгыз хуҗалыкларга .	55	800	—	—	400	550
Казагстан ССР	Колхозларга	50	600	800	1.000	400	1.200
	Ялгыз хуҗалыкларга .	45	500	—	—	300	1.000
Кыргызстан ССР	Колхозларга	60	600	800	1.000	400	1.200
	Ялгыз хуҗалыкларга .	50	500	—	—	300	1.000

Авыл хуҗалыгы культураларының исемнәре	Барлык союзный республикаларда: Колхозларга	Барлык союзный республикаларда: Ялгыз хуҗалыкларга
Колмак (барлык яштәгеләр өчен уртача)	2.800	2.200
Валериана, белладонна, герань, камфаралы базилик, Казанлык розасы, люффа, перилла, арахис, рами, змееголовник	500	400
Ворсоваль шишка (үсуенең 2 нче елыннан страхованиеләнә)	1.000	800
Тәмәке рассадасы, кәбестә, томат һәм башка культуралар рассадалары; виноград питомниклары, җимеш үсемлекләре питомниклары, колмак, чәй һәм башка культуралар питомниклары	10.000	—
Бәрәңге, азык тамырлар (шул исәптән шикәр чөгендере), орлыклык азык тамырлар, чәчелгән үлән орлыклыклары, долгунец җитен, төньяк һәм көньяк киндере, бакун-тәмәке, махорка, кара мальва, наперстянка, мята, шалфей, тмин, далматия ромашкасы, дөге, каучуклы һәм башка культуралар	250	200

11. Терлекләр һәлак булган хәлләрдә страхование акчасы түбәндәге нормалар буенча түләнә (1 терлеккә сумнар белән):

Терлекләрнең төре	Барлык союзный республикаларда: Колхозларга	Барлык союзный республикаларда: Гражданнарның хуҗалыкларына (үз файдалануларында булганнарга)
Мөгезле эре терлек, атлар, качырлар, дөяләр	300	250
Ишәкләр	100	80
Сарыклар һәм кәҗәләр	60	50
Дуңгызлар	80	60
Боланнар	65	—

Искәрмә: 1. 1 яштән алып (ә колхозлардагы яхшы нәселле атларга, дөяләргә һәм ишәкләргә карата 6 айдан алып), 2 яшкә кадәр булган атларны, дөяләрне, ишәкләрне һәм боланнарны, 18 яштән югары булган атларны, шулай ук 6 айлыктан 1 яшкә кадәр булган мөгезле эре терлекләрне страхованиеләү буенча страхование акчасы түләү нормасы 50 процентка кимителә.

Искәрмә: 2. Колхозлардагы 2 яштән югары булган яхшы нәселле атлар, дөяләр һәм ишәкләр, шулай ук 1 яштән югары булган яхшы нәселле мөгезле эре терлек, сарыклар һәм дуңгызлар страхование бәясе буенча тулы бәядә страхованиеләнәләр.

12. Союзный республикаларның халык комиссарлары советларына түбәндәге хокукларны бирергә:

а) авыл хуҗалыгы культураларын страхованиеләү буенча (ст. 10) һәм терлекләрне страхованиеләү буенча (ст. 11) страхование акчасы түләү нормаларын 20 проценттан да артык булмаган күләмдә арттырырга яки киметергә;

б) терлекләрне страхованиеләү буенча һәм авыл хуҗалыгы культураларын страхованиеләү буенча автономияле республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен, өлкәләргә бүленми торган союзный республикаларда районнар өчен страхование акчасы түләү нормаларын билгеләргә.

АССР халык комиссарлары советларына, хезмәт ияләре депутатларының край һәм өлкә советлары башкарма комитетларына, АССР, край һәм өлкә өчен билгеләнгән уртача страхование акчасы нормалары чикләрендә, районнар һәм шәһәрләр өчен нормалар билгеләү хокукы бирергә.

13. Шушы законда күрсәтелгән нормалар буенча страхование акчасын 1941 нче елның 1 нче январеннан башлап булган зарарлар өчен түләргә.

14. Страхование акчасы барлык милек бөтенләй һәлак булганда гына тулы сумада түләнә; зарарлану бер кадәр генә булганда страхование акчасының тиешле өлеше генә түләнә.

Терлекләр һәлак булган хәлләрдә страхование акчасы страхование тәэминаты нормасы күләмендә түләнә, ләкин бу терлекләрнең сәламәт вакыттагы чын бәяләреннән артык булмаска тиеш.

IV. Страхование түләүләре

15. Страхование түләүләре өчен түбәндәге ставкаларны (тарифларны) билгеләргә (страхование тәэминатының 100 сумыннан сумнар белән):

Страхование объектлары	Колхозларда	Колхозчы хуҗалыкларында	Ялгыз хуҗалыкларда
1. Корылышлар, продукция, чимал һәм материаллар:			
а) РСФСР ның һәм БССР ның авыл җирләрендә.	0,80	1,00	1,80
б) УССР ның авыл җирләрендә	0,60	0,90	1,40
в) Азербәйҗан, Грузия, Әрмәнстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казагстан һәм Кыргызстан ССР ларның авыл җирләрендә	0,50	0,70	1,00
г) барлык союзный республикалардагы шәһәрләрдә, эшчеләр поселкыларында һәм шәһәр поселкыларында	0,30	0,50	0,50
2. Инвентарь, җиһазлар һәм транспорт средстволары—барлык союзный республикаларда	0,30	—	—
3. Атлар һәм качырлар—барлык союзный республикаларда	6,00	8,00	14,50
4. Дөяләр һәм ишәкләр—барлык союзный республикаларда	5,00	7,00	9,00
5. Мөгезле эре терлек—барлык союзный республикаларда	2,00	3,00	5,00
6. Сарыклар һәм кәҗәләр—барлык союзный республикаларда	3,00	5,00	7,00
7. Дуңгызлар—барлык союзный республикаларда	4,00	6,00	8,00
8. РСФСР да һәм Казагстан ССР да боланнар	6,00	—	—

(Дәвамы 3 нче биттә).

СССР ның I нче ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ТАРАФЫННАН КАБУЛ ИТЕЛГӘН ЗАКОННАР

МӘҖБҮРИ ОКЛАДНОЙ СТРАХОВАНИЕ ТУРЫНДА ЗАКОН

(Дәвамы)

Страхование объектлары	Колхозларда	Колхозчы хуҗалыкларда	Ялгыз хуҗалыкларда
9. Авыл хуҗалыгы культуралары:			
а) боз сугудан, көчле яңгырлардан, давыллардан һәм ускынды янудан: РСФСР да, Украина, Белоруссия һәм Кыргызстан ССР ларда	1,25	—	2,50
Азербайҗан, Грузия һәм Әрмәнстан ССР ларда	2,50	—	5,00
Төркмәнстан, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Казагстан ССР ларда	0,80	—	1,60
б) Дымланып черүдән, өшүдән, бозылудан, салкыннардан һәм су басудан страхованиеләү буенча: Ужым чәчүлекләре һәм чәчелгән күп еллык үләннәр — барлык союзный республикаларда	3,50	—	9,00
Башка авыл хуҗалыгы культуралары—барлык союзный республикаларда	1,70	—	5,00
10. Балык тоту судноларына—барлык союзный республикаларда	2,00	—	—

16. Шушы законның 5 нче статьясендә әйтелгән авыл хуҗалыгы культураларын страхованиеләү буенча түбәндәгечә страхование түләүләре ставкаларын (тарифларын) билгеләргә (страхование тәэминатының 100 сумыннан сумнар белән):

	Колхозларда	Ялгыз хуҗалыкларда
Мамык: а) РСФСР да һәм Украина ССР да	6,0	10,0
б) Үзбәкстан ССР да	2,5	4,5
в) Азербайҗан, Грузия, Әрмәнстан, Төркмәнстан, Таҗикстан, Казагстан һәм Кыргызстан ССР ларда	3,5	6,0
Гүзәле (сарысы, сигарныкы һәм бакун): а) Грузия ССР да	10,0	15,0
б) РСФСР да	8,0	12,0
в) Украина, Белоруссия, Азербайҗан, Әрмәнстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казагстан һәм Кыргызстан ССР ларда	7,0	10,0
Махорка—барлык союзный республикаларда	6,0	9,0
Шушы законның 5 нче статьясендә әйтелгән башка культуралар—барлык союзный республикаларда	8,0	12,0

17. Эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең һәм кооперативлашкан кустарьларның милкен мәҗбүри рәвештә окладной страхованиеләү буенча колхозчылар хуҗалыклары өчен (хуҗалыкның җәмагатьләштерелмәгән өлеше буенча) билгеләнгән страхование түләү ставкаларын (тарифларын), ә кооперативлашмаган кустарьларның, һөнәрчеләрнең һәм башка гражданнарның милекләрен страхованиеләү буенча ялгыз хуҗалыклар өчен булган ставкаларны кулланырга.

18. Сабан һәм ужым чәчүлекләрен страхованиеләү буенча түләүләрне һәрбер хуҗалыктан чәчү планы буенча исәпләргә, үткән елларда чәчелгән күп еллык үләннәрне страхованиеләү буенча—аларны чабып алу планына карап, ә бакча, җиләклек һәм башка үсемлекләр уңышын страхованиеләү буенча чынлыкта булган мәйданнары буенча исәпләргә.

Планнан тыш чәчелгән мәйданнарны страхование түләүләрен алмыйча страхованиеләргә.

19. а) союзный республикаларның халык комиссарлары советларына, 15 һәм 16 нчы статьяларда күрсәтелгән страхование түләүләренең уртача ставкаларыннан читкә чыкмыйча, автономияле республикалар, крайлар һәм өлкәләр өчен, ә өлкәләргә бүленми торган союзный республикаларда районнар һәм шәһәрләр өчен, ставкалар билгеләү хокукы бирергә;

б) автономияле республикаларның халык комиссарлары советларына, хезмәт ияләре депутатларының край һәм өлкә советлары башкарма комитетларына, уртача ставкалардан читкә чыкмыйча, районнар һәм шәһәрләр өчен ставкалар билгеләү хокукы бирергә;

в) РСФСР Халык Комиссарлары Советына—Ерак Төньяк районнарында терлекчелек колхозлары хуҗалыкларын һәм гражданнарның хуҗалыкларын страхование түләүләреннән бер кадәр яки бөтенләй азат итү хокукы бирергә.

20. СССР Финанс Халык Комиссариатына түбәндәге хокукларны бирергә:

а) корылышларны страхованиеләү буенча корылышларның утка ни дәрәҗәдә чыдамлы булуына карап, страхование түләүләренең уртача ставкаларын ни күбе 30 процентка арттыру яки киметү;

б) аерым урыннар өчен аларны страхованиеләү буенча түләү ставкаларын ни күбе 50 процентка киметү.

21. Мәҗбүри окладной страхование буенча түләүләрне Госстрах органнары исәпли. Страхованиеләүче һәрбер кешегә Госстрах билгеләгән формада анардан күпме алынырга тиешлеге турында түләү кәгазе тапшырыла. Авыл җирләрендә страхованиеләүчеләрдән түләүләр (колхозлардан башка) район финанс бүлекләренең налог агентлары тарафыннан, ә колхозлардан һәм шәһәр җирләрендәге страхованиеләүчеләрдән Госстрах органнары тарафыннан алына.

22. Мәҗбүри рәвештә окладной страхованиеләнергә тиеш булып та яшерелгән яки регистрация вакытында язылмый калган милек табылганда страхование түләүләре шушы милек күпме вакыт исәпкә алынмый торган булса, шул вакыт өчен түләтеләләр, ләкин бу срок 2 елдан да артык булмаска тиеш.

23. Мәҗбүри рәвештә окладной страхованиеләнергә тиеш булган милеккә елына бер тапкыр регистрация ясала. Страхование түләүләре шушы регистрация вактында исәпкә алынган милек буенча исәпләнәләр. Страхованиеләүченең хуҗалыгына регистрациядән соң кергән милек өчен страхование түләүләре бары тик милеккә шуннан соңгы чираттагы учет үткәрелгәннән соң гына түләтеләләр.

24. Зарарлар буенча түләнә торган страхование акчасы сумаларыннан бары тик страхование түләүләре һәм алар буенча недоимкалар гына тотып калына.

25. Мәҗбүри окладной страхование буенча түләүләрне кертү өчен түбәндәге срокларны билгеләргә:

а) колхозлар өчен—түләүләрнең 40 проценты һәр елның 15 нче сентябренә, 30 проценты 1 нче ноябрьгә һәм 30 проценты 1 нче декабрьгә;

б) колхозчылар, эшчеләр, хезмәткәрләр, ялгыз хуҗалыкчы крестьяннар һәм башка гражданнар өчен—түләүнең 50 проценты һәр елның 15 нче сентябренә һәм 50 проценты 1 нче ноябрьгә.

СССР Финанс Халык Комиссариатына—аерым урыннар өчен страхование түләүләре кертүнең башка срокларын билгеләү хокукы бирергә.

26. Срогында кертелмәгән страхование түләүләре недоимка дип исәпләнәләр. Недоимкага кичеккән һәрбер көн өчен түбәндәге күләмдә пеня салына:

а) колхозлардан—0,05 процент;

б) гражданнарның хуҗалыкларыннан—0,1 процент.

27. Мәҗбүри окладной страхование буенча кергән барлык суманың 15 проценты янгыннарны һәм терлекләрнең үлүен булдырмау һәм аңа каршы көрәш расходларына бирелә.

28. Дәүләт страхованиесе буенча масса эше үткәрүгә һәм страхование активын (страхование җәмагать инспекторларын, колхозлардагы страхование постлары членнарын һ. б.) бүләкләүгә мәҗбүри окладной страхование буенча кергән түләүләрнең 0,5 процентын чигерүне билгеләргә.

V. Льготалар

29. Терлекчелекне үстергә булышлык итү теләге белән колхозларга түбәндәге льготаларны бирергә:

а) яхшы нәселле терлекләрне страхованиеләү буенча—страхование түләвеннән 20 процент күләмендә ташлама;

б) товарлыклы фермаларда терлекләрне страхованиеләү буенча—страхование түләвеннән 20 процент күләмендә ташлама;

в) терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын арттырып үтәүче һәм терлекләрне тәрбияләү буенча иң яхшы күрсәткечләре булган колхозларга—терлекләрне страхованиеләгән өчен страхование түләүләренең исәпләнгән сумасыннан 25 процентка кадәр ташлама.

30. Янгыннан саклануның торышы буенча иң яхшы күрсәткечләре булган һәм утка чыдамлы (черепица, калай, шифер һ. б.) түбәле корылышлар салучы колхозлар корылышларны, инвентарьны, җиһазларны, транспорт средстволарын, продукцияне, чималны һәм материалларны страхованиеләү буенча исәпләнгән түләүләр сумасыннан 50 процентка кадәр ташлама алалар.

31. 29 нчы статьянең „в" пунктында һәм 30 нчы статьяда күрсәтелгән ташламалар күләме аерым колхозларга карата хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының карарлары белән, колхозларда страхованиеләнгән милекләрнең хәлен тикшерү актлары нигезендә билгеләнә.

32. 6 айлыктан 1 яшькә кадәр булган мөгезле яшь эре терлекләр һәм бер яштән 2 яшькә кадәр булган яшь атлар, дөяләр, ишәкләр, качырлар һәм боланнар (ә яхшы нәселле яшь атларның, дөяләрнең һәм ишәкләрнең 6 айлыктан 2 яшькә кадәр булганнары) страхование түләүләре алынмыйча страхованиеләнәләр.

33. Хезмәт ияләре депутатларының район һәм шәһәр советларының башкарма комитетлары, Госстрах органнарының күрсәтүе буенча, кайбер гражданнарның хуҗалыкларын мәҗбүри окладной страхованиеләү буенча страхование түләүләреннән бер кадәр һәм бөтенләй азат итә алалар.

34. Күчеп утыручылар, шулай ук күчеп утыручылардан яңа оештырыла торган колхозлар яки күчеп утыручыларны үз составларына кабул итүче колхозлар күчеп утырган урыннарында СССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының „Авыл хуҗалыгында күчеп утыру буенча льготалар турында" 1937 нче елның 17 ноябрендә чыгарылган 115/2043 нче номерлы карары буенча (СССР Законнар Җыентыгы, 1937 ел, №73, ст. 352) страхование түләүләреннән азат ителәләр.

35. Колхозларга шул елның 15 нче сентябренә кадәр кергән хуҗалыкларның җәмагатьләштерелмәгән милекләрен страхованиеләү буенча страхование түләүләре колхозчыларның хуҗалыклары өчен билгеләнгән ставкалар (тарифлар) буенча исәпләнә.

VI. Страхованиеләүчеләрнең йөкләмәләре

36. Колхозлар һәм башка страхованиеләүчеләр милекләрен һәм чәчүлекләрен тулы тәртиптә һәм янгынга каршы, агрономия һәм ветеринария кагыйдәләренә бик нык туры килә торган рәвештә тотарга, янгыннарны, терлекләрнең авыруларын һ. б. булдырмау өчен кулларыннан килгән барлык чараларны күрергә тиешләр.

37. Страхованиеләнгән милекнең табигый бәләләрдән һәлак булуы яки зарарлануы турында страхованиеләүчеләр: колхозлар авыл советына һәм страхование инспекторына, колхозчылар һәм ялгыз хуҗалыкчылар авыл советына хәбәр итәргә тиешләр. Бу белдерүләр түбәндәге срокларда да соңга калмыйча ясалырга тиеш:

а) корылышлар һәм башка төрле милекләр янгыннан, су басудан һәм башка шундыйлардан һәлак булганда, шулай ук терлекләр үлгәндә—табигый бәлә яки бәхетсезлек вакыйгасе булу көненнән бер тәүлектән дә соңга калмыйча;

б) балык тоту суднолары һәлак булганда яки зарарланганда—табигый бәлә булган көннән 5 тәүлектән дә соңга калмыйча;

в) авыл хуҗалыгы культуралары һәлак булганда яки зарарланганда—аларның зарарланулары яки һәлак булулары билгеләнгән көннән 5 тәүлектән дә соңга калмыйча.

Терлекләрнең үлүе турындагы белдерүләрдән тыш (ст. 38) страхованиеләүчеләрдән кергән белдерүләр турында авыл советлары икенче көннән дә соңга калмыйча район страхование инспекциясенә хәбәр итәргә тиешләр.

VII. Зарарлар турында актлар төзү тәртибе

38. Авыл җирләрендә страхованиеләнгән терлекләр үлгән хәлләрдә актларны хезмәт ияләре депутатларының авыл советы башкарма комитеты председателе яки авыл советының аның тарафыннан хокук бирелгән депутатлары, шәһәр җирләрендә—страхование инспекторлары яки ветеринария врачлары төзи. Актлар төзегәндә түбәндәгеләр әлбәттә катнашалар: колхозда зарар булганда правление председателе яки правлениенең махсус билгеләнгән члены, ә колхозчы хуҗалыгында яки ялгыз хуҗалыкта зарар булганда хуҗалыкның башлыгы яки семьянең яше җиткән члены. Актлар ике шаһит катнашы белән төзеләләр.

39. Корылышлар, инвентарь, авыл хуҗалыгы культуралары, балык тоту суднолары һәм башка милекләр һәлак булганда яки зарарланганда, актларны Госстрах органнары төзи. Актларны төзегәндә страхованиеләүче үзе (ст. 38), авыл советы вәкиле һәм ике шаһит, ә авыл хуҗалыгы культуралары һәлак булганда шулар өстенә агроном да, әлбәттә, катнашырга тиеш.

40. Әгәр дә страхованиеләнгән милекнең һәлак булуы яки зарарлануы колхоз правлениесенең гаебе белән, ә гражданнарның хуҗалыкларында страхованиеләүченең яки аның семьясендә яше җиткән членның гаебе белән килеп чыккан барлык хәлләрдә Госстрах зарарларны түләми.

41. Түләнгән страхование акчасын страхованиеләнгән милекнең һәлак булуында яки зарарлануында гаепле булган кешедән кире түләтү турында халык судына мөрәҗәгать итәргә Госстрахның хокукы бар.

42. Әгәр дә страхованиеләүче мөмкинлеге була торып та страхованиеләнгән милекнең һәлак булуы яки зарарлануы турында билгеләнгән срокта (ст. 37) хәбәр итмәсә Госстрахның страхование акчасын түләүдән баш тартырга хокукы бар.

VIII. Мәҗбүри окладной страхованиене үткәрү тәртибе

43. Мәҗбүри окладной страхование шушы законга туры китереп һәм шуның нигезендә союзный һәм автономияле республикаларның халык комиссарлары советлары тарафыннан чыгарылган карарларга һәм хезмәт ияләре депутатларының край һәм өлкә советлары башкарма комитетларының карарларына туры китереп үткәрелә.

44. Союзный республикаларның халык комиссарлары советларына мәҗбүри окладной страхование турында 10 көн срок эчендә карарлар чыгарырга һәм иглан итәргә тәкъдим итәргә.

45. Шушы закон чыгу белән түбәндәгеләрне юкка чыгарырга:

а) „Мәҗбүри окладной страхование кагыйдәләрен раслау турында" СССР Совнаркомының 1933 нче ел 28 нче май карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1933 ел, № 34. ст. 201-а, 201-б);

б) „Авыл җирләрендә һәм шәһәрләрдә 1935 нче елга мәҗбүри окладной страхование турында" СССР Совнаркомының 1934 нче елның 19 нчы июль карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1934 ел, № 38, ст. 308), шулай ук „1936 нчы елга мәҗбүри окладной страхование турында" СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 2 нче август карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1935 ел, № 41, ст. 347), „Мәҗбүри окладной страхование турында" 1936 нчы ел, 14 нче июль карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1936 ел, № 37, ст. 325) һәм „ССР Союзы Совнаркомының „Авыл җирләрендә һәм шәһәрләрдә мәҗбүри окладной страхование турында" 1934 нче ел, 19 нчы июль карарын үзгәртү турында" 1937 нче ел, 4 нче август карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1937 ел, № 50, ст. 211);

в) „Район страхование комиссияләре турында" СССР Совнаркомының 1936 нчы ел 5 нче апрель карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1936 ел, № 18, ст. 159);

г) „ССР Союзы Финанс Халык Комиссариатының Авыл җирләрендәге район финанс бүлекләренең страхование инспекцияләренең эше турындагы инструкциясен раслау турында" СССР Совнаркомының 1937 нче ел, 29 нчы апрель карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1937 ел, № 30, ст. 125).

„СССР Совнаркомының авыл җирләрендә һәм шәһәрләрдә мәҗбүри окладной страхование турында" гы 1934 нче ел 19 нчы июль карарын үзгәртү турында „СССР Совнаркомының 1938 нче ел, 7 нче октябрь карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1938 ел, № 45, ст. 269) һәм „Житен һәм киндер чәчүлекләрен, кызыл клевер орлыклыкларын корылыктан һәм махсус һәм техник авыл хуҗалыгы үсемлекләренең аерым төрләрен корткычлардан һәм үсемлек авыруларыннан мәҗбүри рәвештә окладной страхованиеләүне бетерү турында" 1939 нчы ел 5 нче январь карары (СССР Законнар Җыентыгы, 1939 ел, № 4, ст. 16) гамәлдән чыккан дип санарга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 4 апрель. 1940 ел.

СССР КОНСТИТУЦИЯСЕНӘ (ТӨП ЗАКОНЫНА) 29-а ҺӘМ 29-б СТАТЬЯЛӘРЕ КЕРТҮ ҺӘМ 22, 23, 27, 28, 29 ҺӘМ 77 НЧЕ СТАТЬЯЛӘРЕНӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА ЗАКОН

Совет Социалистик Республикалар Союзының Верховный Советы **карар бирә:**

1. Төркмәнстан Совет Социалистик Республикасы составында Ашхабад, Красноводски, Мары, Ташауз һәм Чарджоу өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенә 29-а статьясен өстәргә, аны түбәндәгечә язарга:

„**Статья 29-а.** Төркмәнстан Совет Социалистик Республикасында: Ашхабад, Красноводски, Мары, Ташауз һәм Чарджоу өлкәләре торалар".

2. Кыргызстан Совет Социалистик Республикасы составында Фрунзе, Иссык-Күл, Тянь-Шань, Җәләл-Абад һәм Ош өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенә 29-б статьясен өстәргә, аны түбәндәгечә язарга:

„**Статья 29-б.** Кыргызстан Совет Социалистик Республикасында: Җәләл-Абад, Иссык-Күл, Ош, Тянь-Шань һәм Фрунзе өлкәләре торалар".

3. Карелия Автономияле Совет Социалистик Республикасын Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү һәм Пермь өлкәсенең исмен Молотовски өлкәсе дип үзгәртү уңае белән СССР Конституциясенең 22 нче статьясенә тиешле үзгәрешләрне кертергә, аны түбәндәгечә язарга:

„**Статья 22.** Россия Совет Федератив Социалистик Республикасында: Алтай, Краснодар, Красноярски, Орджоникидзе, Приморье, Хабаровски крайлары; Архангельски, Вологда, Воронеж, Горький, Иваново, Иркутски, Калинин, Киров, Куйбышев, Курски, Ленинград, Молотовски, Москва, Мурман, Новосибирски, Омски, Орел, Пенза, Ростов, Рязан, Саратов, Свердловски, Смолински, Сталинград, Тамбов, Тула, Чилябе, Чита, Чкалов, Ярославль өлкәләре; Татарстан, Башкыртстан, Дагыстан, Бурят-Монголия, Кабардино-Балкария, Калмык, Коми, Кырым, Мари, Мордва, Волга буе Немецләре, Төньяк Осетин, Удмурт, Чечен-Ингушия, Чувашстан, Якутия автономияле совет социалистик республикалары; Адыгей, Еврей, Карачай, Ойрот, Хаккас, Черкас автономияле өлкәләре торалар".

4. Украина Совет Социалистик Республикасы составында Волын, Дрогобычи, Львов, Ровно, Станислав һәм Тарнополь өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенең 23 нче статьясен түбәндәгечә язарга:

„**Статья 23.** Украина Совет Социалистик Республикасында: Винница, Волын, Ворошиловград, Днепропетровски, Дрогобычи, Житомир, Запорожье, Каминец-Подольски, Киев, Кировоград, Львов, Николаевски, Одесса, Полтава, Ровно, Сталино, Станислав, Сумы, Тарнополь, Харьков, Чернигов өлкәләре һәм Молдавия Автономияле Совет Социалистик Республикасы торалар".

5. Таҗикстан Совет Социалистик Республикасы составында Сталинабад, Ленинабад, Куляб һәм Гарм өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенең 27 нче статьясен түбәндәгечә язарга:

„**Статья 27.** Таҗикстан Совет Социалистик Республикасында: Гарм, Куляб, Ленинабад, Сталинабад өлкәләре һәм Таулы-Бадахшан автономияле өлкәсе торалар".

6. Казагстан Совет Социалистик Республикасы составында Семипалатински, Акмолински һәм Җамбул өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенең 28 нче статьясен түбәндәгечә язарга:

„**Статья 28.** Казагстан Совет Социалистик Республикасында: Акмолински, Актүбә, Алма-Ата, Көнчыгыш Казагстан, Гурьев, Җамбул, Көнбатыш Казагстан, Караганды, Кызыл Орда, Кустанай, Павлодар, Төньяк Казагстан, Семипалатински, Көньяк Казагстан өлкәләре торалар".

7. Белоруссия Совет Социалистик Республикасы составында Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка һәм Пински өлкәләре төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенең 29 нчы статьясен түбәндәгечә язарга:

„**Статья 29.** Белоруссия Совет Социалистик Республикасында: Барановичи, Белосток, Брест, Вилейка, Витебски, Гомель, Мински, Могилев, Пински һәм Полесье өлкәләре торалар".

8. Гомуми-Союз Халык Комиссариатлары: СССР Күмер Промышленносте Халык Комиссариаты; СССР Нефть Промышленносте Халык Комиссариаты төзелүне расларга.

Шуңа туры китереп СССР Конституциясенең 77 нче статьясен түбәндәгечә язарга:

„**Статья 77.** Гомуми-Союз Халык Комиссариатларына:

Оборона;
Чит Ил Эшләре;
Тышкы Сәүдә;
Юл Эшләре;
Элемтә;
Диңгез Флоты;
Елга Флоты;
Күмер Промышленносте;
Нефть Промышленносте;
Электростанцияләр һәм Электр Промышленносте;
Кара Металлургия;
Төсле Металлургия;
Химия Промышленносте;
Авиация Промышленносте;
Суднолар Төзелеше Промышленносте;
Сугыш Кирәк Яраклары;
Кораллар;
Авыр Машина Төзелеше;
Уртача Машина Төзелеше;
Гомуми Машина Төзелеше;
Хәрби Диңгез Флоты;
Хәзерләүләр;
Төзелеш-Халык Комиссариатлары керәләр".

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 4 апрель, 1940

„УКРАИНА СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ БЕЛӘН БЕЛОРУССИЯ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ АРАСЫНДА ӨЛКӘЛӘРНЕ ЧИКЛӘҮ ТУРЫНДА" СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫН РАСЛАУ ТУРЫНДА

Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы **карар бирә:**

„Украина Совет Социалистик Республикасы белән Белоруссия Совет Социалистик Республикасы арасында өлкәләрне чикләү турында" СССР Верховный Советы Президиумының 1939 нчы ел 4 нче декабрь указын расларга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 4 апрель, 1940 ел.

СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЛАРЫН РАСЛАУ ТУРЫНДА

Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный Советы СССР Верховный Советы Президиумының:

Төзелеш Халык Комиссары итеп Семен Захарович **Гинзбургны,**

СССР ның Сәламәтлек Саклау Халык Комиссары итеп Георгий Андреевич **Митеревны,**

СССР ның Нефть Промышленносте Халык Комиссары итеп Лазарь Моисеевич **Кагановичны,**

СССР ның Күмер Промышленносте Халык Комиссары итеп Василий Васильевич **Вахрушевны,**

СССР ның Авиация Промышленносте Халык Комиссары итеп Алексей Иванович **Шахуринны,**

СССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Комитеты председателе итеп Михаил Борисович **Храпченконы,**

Хәзерләүләр Халык Комиссары итеп Владимир Александрович **Донскойны,**—билгеләү турындагы указларын расларга.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 4 апрель, 1940 ел.

Чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейде

Фикерләр һәм чынбарлык

Әгерҗе районында эшче-авыл хәбәрчеләре рейде бригадасы „III Интернационал" колхозында язгы чәчүгә хәзерлекнең торышын тикшерде. Биредә орлыклар яхшы һәм коры урыннарда саклаңалар. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт төгәлләнгән. Атларның күпчелеге яхшы һәм уртача көрлектә. Чәчү вактында атларга ашату өчен азык җитәрлек хәзерләнгән. Сбруйлар һәрбер атка 2 комплект.

Бригада бу колхозда язгы чәчүгә хәзерлектә күп кенә җидди кимчелекләрне дә ачты. Мәсәлән, бодайның 90 центнеры, солының 205 центнеры тиешле кондициядә түгел. Мондый чәчүгә яраксыз орлыклар бу колхозда 300 центнер чамасы бар. Бу орлыкларны яхшы орлыкка алмаштыру турында колхоз җитәкчеләре бригада килгәнчегә кадәр уйлап та карамаганнар. 14 центнер житен һәм 10 гектар мәйданга силос орлыклары да җитми. Кышкы агрономия чаралары планы үтәлмәгән.

Хезмәтне оештыруда һәм масса-аңлату өлкәсендә дә житешсезлекләр юк түгел. Даими звенолар формаль рәвештә генә оештырылганнар. Аларга участкылар беркетелмәгән. Колхозның производство планы гомуми җыелышта тикшерелмәгән .Колхоз бер колхоз белән дә ярышмый. Колхозчылар арасында да индивидуаль ярыш договорлары төзелмәгән. Шунсы гаҗәп, район оешмалары бу колхозны язгы чәчүгә тулысынча хәзер дип исәпләп килгәннәр.

Рейд бригадасы бу житешсезлекләрне бетерү буенча тиешле тәкдимнәр ясады. Тикшерү нәтиҗәсе колхоз правлениесе утырышында һәм колхозчыларның гомуми җыелышында тикшерелде.

Рейд бригада членнары:
Хәбибуллин, Неклюдов, Аббасов, Ганеева, Бородина, Караев.

Ике колхоз—ике нәтиҗә

ДӨБЪЯЗ, 5 апрель. (Телефон буенча). Дөбъяз районының барлык колхозларында эшче-авыл хәбәрчеләре рейде бара.

„Чөрнаш" колхозында оештырылган бригадада (җитәкчесе хәбәрче иптәш Гәрәев) колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген аеруча зур игтибар белән тикшерә. Правлениедә колхозның язгы чәчүгә тулы хәзерлеге турында әйттеләр. Ләкин рейд бригадасы күп кенә кимчелекләрне ачты. Мәсәлән, колхозда яшелчә орлыклары җитешми. Рейд бригадасы бу орлыкларны булдыруга ярдәм итте. Хәзер 12 килограмм турнипс орлыгы кайтарылды.

Даими звенолар формаль рәвештә генә төзелгән. Звено членнары звенода күпме чәчү мәйданы һәм инвентарьлар барлыгын да белмиләр. Звенолар арасында социалистик ярыш оештырылмаган. Яровойлаштыру эшенә урын хәзерләнмәгән. Бу кимчелекләрне ашыгыч бетерү өчен бригада конкрет чаралар билгеләде.

„Кызыл байрак" колхозында оештырылган рейд бригадасы (бригада җитәкчесе хәбәрче иптәш Ибраһимов) колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген яхшы дип тапты. Бу колхозда чәчү орлыклары тулысынча хәзерләнгән, алар барсы да сортлы, коры урында саклаңалар.

Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт тулысынча үткәрелеп, алар акт белән бригадаларга тапшырылган. Колхозда яшелчәлек эше аеруча яхшы куелган. Кирәкле орлыклар һәм парниклар бар. Иртә өлгерешле яшелчәләрдән кәбестә, кыяр, суган һәм башкалар яхшы үсәләр. Бу эштә 6 елдан бирле эшләүче стахановчы иптәш Хәбибуллина гүзәл эш үрнәкләре күрсәтә.

Ләкин әле колхозның уңышлы яклары белән бергә, язгы чәчүгә хәзерлектә кимчелекләре дә бар. Атларның күбесе ябык.Рейд бригадасы члены иптәш Хәбибуллина атларны группага бүлү һәм ат карауччылар арасында социалистик ярыш оештыру эшләрен алып бара.

Надиров.

Тревогалы хәл

НОРЛАТ, 8 апрель. (Махсус хәбәрчебездән телеграф буенча). Рейд бригадасы Октябрь МТС ында язгы чәчүгә хәзерлек буенча тревогалы хәлләрне ачты һәм аларны бетерү өчен конкрет тәкдимнәр ясады.

МТС та бу эш болай тора. Анын 66 тракторы бар. Татнаркомзем 8 тракторны ремонт планыннан бөтенләй төшереп калдырган. МТС та 19 тракторга ремонт ясыйсы бар. Ремонт барышы турында сводка биргәндә бу 8 трактор бөтенләй төшереп калдырыла. Шулай итеп МТС директоры иптәш Биляев күз буяучылык белән шөгыльләнә. Ул барлык тракторларны да тизрәк ремонтлауда конкрет чаралар күрми.

Ремонттан чыккан, исәплә колхозларга җибәрелгән 3, 6, 14 һәм 19 нчы номерлы тракторларның радиаторлары эшкә ярарлык түгел. 3, 16 һәм 26 нчы номерлы тракторларның сепараторлары начар. 6 нчы бригадага 2 тракторның фарлары юк. У—2 тракторларының прицепкалары яраксыз.

МТС та 6 бригада культура вагоннары белән тәэмин ителмәгән. Бригадирлар һәм тракторчылар арасында хезмәт дисциплинасы начар. Машиналарны саклауга әһәмият бирелми. Иптәш Биляев бригадасының тагылма инвентарьлары җыелмаган килеш теләсә кайда аунап яталар.

У. Әхметов.

Язгы сөрү башланды

ПУЧЫ. (Телефон буенча). Калинин районының Маркс исемендәге колхозында 6 нчы апрельдә барлык бригадалар да язгы сөрүгә чыктылар.

Районның барлык колхозлары да чәчүлек орлык белән тулысынча тәэмин ителде.

Гыйлметтинов.
Район җир бүлеге мөдире.

Казан МТМ ның стахановчы токаре А. Разумкова. Ул Татарстанның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышка кушылды һәм планны 300 процент үтәп килә.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы)

КЫР ЭШЛӘРЕ БАШЛАНУ АЛДЫННАН

КРАСНЫЙ БОР. (Телефон буенча). Районның Салауш ягында басулар кардан чистарды. Шушы көннәрдә кыр эшләре башлану көтелә. Ә менә районның Исәнбай МТС ы исә язгы кыр эшләренә һаман да хәзер түгел әле. 5 тракторга һәм 6 чәчү машинасы прицепкаларына ремонт төгәлләнмәгән. Тагылма машиналарда эшләүчеләр турында МТС работниклары хәзергә кадәр уйлап та караганнары юк. МТС җитәкчеләре (директоры Камалов, партия оешмасы секретаре Насыйров, өлкән агроном Еруcланов) тракторлар белән иртә культуралар чәчүне 14 көн эчендә төгәлләүне планлаштырганнар. Партиянең район комитеты бу планны тикшерде һәм МТС дирекциясенә планны яңадан төзәргә такдим итте.

Әбҗәлимов.

БАУЛЫ. (Телефон буенча). Запас частьләр җитәрлек хәзерләнмәү нәтиҗәсендә МТС ның 6 данә дизель тракторларына ремонт һаман да төгәлләнмәгән.

Районда күп кенә колхозларда атларның торышы яхшы түгел. „Йолдыз" һәм Куйбышев исемендәге колхозларда атларның көрлеге бигрәк тә түбән.

Шәрәфеттинов.

НОРЛАТ. (Телефон буенча). „Алга", „Совет", „Активист", Киров һәм Молотов исемендәге колхозларда бәрәңгене яровойлаштыруга салдылар. Яровойлаштыру өчен урыннар җитәрлек. Агулау материаллары да бар. Барлык колхозларда да авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт төгәлләнде. Куйбышев исемендәге колхозда ремонтның сыйфаты начар иде. Район җир бүлеге бу эшне тикшерде һәм яңадан ремонт ясарга такдим итте. Ләкин кайбер колхозларда атларның торышы мактарлык түгел.

Краюшкин.
Район җир бүлегенең баш агрономы.

Москвада татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы

4 нче апрельдә Москвага татар язучыларыннан Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт, Муса Җәлил, Афзал Шамов, Газый Кашшаф һәм Т. Имаметтинов иптәшләр килделәр.

Казан вокзалында кунакларны СССР Совет Язучылары Союзының милли-әдәбият секторы вәкилләре, татар язучыларыннан: Әхмәт фәйзи, Салих Баттал, Әхмәт Ерикәй иптәшләр, Москвадагы татар культура йорты работниклары, укытучылар, студентлар, эшчеләр каршыладылар.

Шул ук кичне язучылар клубында Ш. Камалның 30 еллык әдәби эшчәнлегенә багышланган кичә үткәрелде. Кичәне язучы Константин Федин ачты. Ул үзенең кереш сүзендә Ш. Камалның татар әдәбиятында нинди зур хезмәт итүен күрсәтеп үтте. Шәриф Камалның белем артыннан, бәхет эзләп дөнья гизүен матур итеп сурәтләде. Каләм остасының Октябрь кояшы астында чәчәк аткан үз илендә чын бәхеткә ирешкәнлеген күрсәтте.

Татарстан Совет Язучылары Союзының җаваплы секретаре шагыйрь Муса Җәлил Ш. Камалның иҗады турында доклад ясады.

Кичәнең художество бүлегендә Татар Дәүләт Академия театры артистларының көче белән Ш. Камалның „Хаҗи әфәнде өйләнә" комедиясеннән бер пәрдә күрсәтелде.

Язучыны хөрмәтләп аның җылы сүзләрен тынларга килүчеләр белән зал шыгрым тулы иде.

А.

ҖӘЙГЕ ҺАВА ЮЛЛАРЫ АЧЫЛУГА ХӘЗЕРЛЕК

Казан аэропортында җәйге һава юллары ачылуга карата хәзерлек эше җәелде. Техник-эксплоатация работниклары, 1940 нчы елның җәендә Москва—Иркутский һава линиясе магистралендә эксплоатациялэнәчәк яңа самолетларның материал частьләрен өйрәнәләр. „ПС—84" дигән яңа самолет өйрәнелә. Ул Москва белән Новосибирский арасында пассажирлар йөртәчәк.

Аэропортның элемтә работниклары барлык самолетларны ике яктан да ышанычлы элемтә белән һәм радиомаяк зонасы белән тәэмин итү өчен радиостанция аппаратурасын һәм радиомаякны хәзерлиләр.

Аэропортта гостиница, ашханә, буфет һәм көтеп тору залы җиһазландырыла.

(ТатТАСС).

ШАШКА-ШАХМАТ ЯРЫШЛАРЫ

Физкультура һәм спорт эшләре буенча Казан шәһәр комитеты спорт җәмгыятьләре беренчелеге өчен командалар арасында шашка-шахмат ярышлары үткәрде. 6 нчы апрельдә ярышларның соңгы партиясе уйналды.

Ярышларда барлыгы 12 җәмгыяттән 200 дән артык шашкачы һәм шахматчы катнашты. Һәрбер җәмгыят 11 шахматчы һәм 6 шашкачыдан торган берәр команда куйды.

Финалга 3 спорт җәмгыяте—„Спартак", „Наука" һәм „Учитель" җәмгыятьләре чыкты. Финал уенында беренче урынны „Спартак" җәмгыятенең командасы алды. Ул 28 партиядән 18 очко җыйды. 2 нче урынга „Наука" җәмгыятенең командасы (14,5 очко) чыкты.

Ярышларда җиңеп чыккан „Спартак" командасына шәһәр комитетының күчмә призы бирелде.

ХУДОЖЕСТВО СҮЗЕ МАСТЕРЫ В. БОЛХОВСКОЙ ЧЫГЫШЛАРЫ

Татарстан Дәүләт филармониясенең чакыруы буенча Казанга художество сүзе мастеры В. Болховской килде.

5 нче апрельдә Казанның Менжинский исемендәге клубында Болховской катнашы белән рус әдәбиятына багышланган кичә үткәрелде. Кичәдә Болховской А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Лев Толстой, М. Горький, Гоголь, Маяковский, Зощенко, Алексей Толстой һәм башка язучыларның әсәрләрен укыды.

Чит илләрдә

ФРАНЦИЯНЕҢ КОММУНИСТ ДЕПУТАТЛАРЫНА СУД ПРОЦЕССЫ

БРЮССЕЛЬ, 7 апрель. (ТАСС). Хәзер мәгълүм булганча, Франциянең коммунист депутатлары процессында гаепләнүче Бийу соңгы сүзне әйтүдән баш тарткан гаепләнүчеләр исеменнән манифест игълан иткән. Бу документта хәзерге сугышка империалистик сугыш дип һәм Франциянең идарәче даирәләренең тышкы политикасына бөтен дөнья күләмендә империалистик сугышны чишеп җибәрүгә һәм Советлар Союзына каршы поход оештыруга юнәлдерелгән политика дип характеристика бирелә. Франция хөкүмәтенең эчке политикасына ачыктан-ачык реакцион диктатура политикасы дип характеристика бирелә.

Процесста шаһитләр сыйфатында Лорд Фарингдон һәм профессор Ланжевен чыкканнар. Фарингдон „бу процесс Англия халкы алдында Франциянең дәрәҗәсен төшерде" дип белдергән. Ул, коммунист депутатларны судка бирү фактына үзенең төшенмәгәнлеген, шулай ук аларны Эрриога мөрәҗәгатькә кул куюда гаепләүгә төшенмәгәнлеген белдергән.

Профессор Ланжевен шаһитлек күрсәтүләре биргәндә үзенең марксист икәнлеген әйткән. Ул, Маркс теориясенең алдынгылык ролен, гаепләнүчеләрнең шул теориясе дәвам иттерүчеләр икәнлеген һәм физика өлкәсендә күп кенә яңалыкларны үзенең марксистик методтан файдалануы аркасында ачканлыгын белдергән.

Скандинавия илләренә Англиянең һәм Франциянең басымы

СТОКҺОЛЬМ, 6 апрель. (ТАСС). „Дагенс нюхетер" газетасының язуына караганда, кичә Англиянең чит ил эшләре министре Галифакс Швециянең һәм Норвегиянең Лондондагы илчеләрен кабул итеп, аларга үзләренең хөкүмәтләренә тапшыру өчен нота биргән. Нотаның эчтәлеге турында хәбәрләр юк. Ләкин, әйтүләренә караганда, нотаның тәлгәге Швециянең һәм Норвегиянең нейтралитет позицияләре уңае белән аларның хөкүмәтләренә басым ясаудан гыйбарәт.

ПАРИЖ, 6 апрель. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда Франциянең баш министре Рейно кичә Швеция һәм Норвегия илчеләрен кабул иткән һәм аларга ноталар тапшырган. Агентлыкның белдерүендә, бу ноталарның тәлгәге „Скандинавия илләренең нейтралитеты уңае белән союзникларның позициясен аңлату" диелә.

ТӨРКИЯДӘ СУ БАСУ

ӘНКАРА, 7 апрель. (ТАСС). Озак яңгырлар булу һәм кар эрү аркасында Яшел—Ермак елгасы берничә районда ярларыннан чыкты. Амасия вилаятендә 30 лап авыл, болыннар, виноград бакчалары су астында калган. Амасия шәһәрендәге йортларның беренче этажларын су баскан. Самсун районында да бакчаларны, чәчүлекләрне һәм берничә авылны су баскан. Токат вилаятендә берничә ун мең гектар чәчүлек су астында калган. Берничә күпер җимерелгән. Турхал шәһәре тулысынча су астында калган. Бу шәһәрнең халкы күчерелгән. Бу вилаятлар аркылы үтүче башка елгалар да ярларыннан чыкканнар. Су басу аркасында Сивас белән Самсун арасындагы тимер юл өзелгән.

ИСПАНИЯДӘГЕ ХӘЛ ТУРЫНДА АМЕРИКА ЖУРНАЛЫ

НЬЮ-ЙОРК, 6 апрель. (ТАСС). „Тайм" журналында Испаниянең экономик хәле авыр булу турында мәкалә урнаштырылган. Сугыш тукталганнан бирле туеню продуктларының һәм киң куллану әйберләренең бәясе ике тапкыр арткан. Иң әһәмиятле туену продуктларының җитешмәве сизелә.

Минераллар житештерү сугышка кадәрге вакыт белән чагыштырганда 75 процентка кимегән.

Журналның язуынча, Испаниядә 1 миллион 250 мең эшсез бар. 1 миллион чамасы кеше төрмәләргә ябылган.

АКШ та компартияне эзәрлекләү

НЬЮ-ЙОРК, 5 апрель. (ТАСС). АКШ та коммунистик партиягә каршы кампания көчәя. 2 нче апрельдә вәкилләр палатасы партиянең членнар саны турындагы мәгълүматны әйтүдән баш тарткан өчен Көнбатыш Пенсильвания оешмасы секретаре Пауэрсны җавапка тартуны таләп итеп, судка мөрәҗәгать иткән. Дайс комиссиясе агентлары феладельфиядә компартия бинасына һөҗүм иткәннәр. Сан-Францискода чыга торган „Пиплс уорлд" газетасының хәбәр итүенә караганда, җирле властьлар Калифорния оешмасы секретаре Шнейдерманны, гүяки моннан 12 ел элек Америка гражданы дигән исемне алган вакытта ялган күрсәтмәләр бирүдә гаепләп, Америка гражданлыгыннан мәхрүм итәргә маташалар. Калифорния властьлары шулай ук компартиянең шул ук штаттагы оешмасының элекке секретаре Дарсины АКШ тан сөрергә маташалар.

Редактор урынбасары
И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

НОРВЕГИЯНЕҢ ЧИТ ИЛ ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЕ КУТНЫҢ РЕЧЕ

ОСЛО, 7 апрель. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, чит ил эшләре министре Кут Норвегиянең тышкы политикасы турындагы мәсьәлә буенча 6 нчы апрельдә стортингда белдерү ясады. Ул болай диде:

„Без, үзебезнең бәйсезлегебезне һәм азатлыгыбызны яклау өчен чыгарга тиеш булган сугыштан башка, Норвегиянең нинди булса да сугышка чыгуы турында уйлый алмыйбыз. Без үзебезне сугыштан бары тик барлык өлкәләрдә нык нейтралитет политикасы үткәрү юлы белән генә коткара алабыз. Сәүдә политикасында без моны эшләдек инде, анда барлык мәсьәләләр, мөмкин булган кадәр нормаль сәүдәне яклау принципына нигезләп, сугышучы державалар белән килешү юлы белән тәртипкә салыналар.

Без, үзебезнең территориаль суларыбызны законсыз рәвештә үтеп керергә маташучыларның барсыннан да саклаячагыбызны күрсәттек. Швеция рудасын Нарвик аркылы Германиягә чыгаруны, һич шиксез, күп кешеләр арттырып күрсәтәләр. Германиягә чыгарыла торган Швеция рудасы, сугыш вактында дүрттән бер тапкыр киметелде, һәм хәзер Швеция рудасының шактый өлеше Нарвик аркылы Англиягә китә. Норвегия сулары аркылы сәүдә пароходларының ирекле рәвештә үтү хокукы союзниклар өчен дә Германия өчен булган кебек үк файдалы. Безнең сәүдә дә, шулай ук Швеция сәүдәсе дә, сугышучы державалар белән төзелгән килешүләр нигезендә тәртипкә салына".

Аннары Кут болай диде: „Әгәр дә союзниклар, безнең халыкара хокуклар нормаларына туры китереп, гомумән танылган нормаларга туры китереп, шул исәптән Англия һәм Франция тарафыннан танылган нормаларга туры китереп үткәрелә торган ирекле сәүдәбезне туктатырга телиләр икән, ул вакытта бу аларның үзләренә зур зиан китерер иде. Әгәр дә бу туктату бары тик бер генә якка каршы юнәлдерелгән булса, мондый чара безнең нейтралитетыбызга тулысынча каршы килер иде һәм безнең илебез бик тиздән белән сугыш хәлендә булыр иде".

Аннары Кут, чит ил самолетларының Норвегиянең нейтралитетын бозуларына каршы Норвегия хөкүмәтенең сугышучы илләргә берничә тапкыр протест белдергәнлеген искә алды. Кут болай диде: „Соңгы көннәрдә чит ил самолетларының Норвегиянең нейтралитетын бозулары очраклы хәл булмаган булырга тиеш. Без моны Лондонда һәм Берлиндә аңлаштык һәм сугышучы илләр бу практикага чик куярга тиешләр дип ышанабыз, чөнки бу политика сугыш максатларына бернинди файда китермәячәк. Үз чиратыбызда исә без протестлар җибәрү белән генә чикләнеп кала алмаячакбыз һәм мондый самолетларны бәреп төшерәчәкбез".

Кут, моңа кадәр булган инцидентларның „Альтмарк" белән булган вакыйга кебек зур булмаганлыкларын әйтте. Ул болай диде: „Бу инцидентка бәйле булган күп кенә мәсьәләләр буенча Англия белән Норвегия хөкүмәтләре арасында килешүгә ирешелгән булса да, шулай да халыкара хокукка караган бер мәсьәлә аңлашылмыйча калды".

Ачык диңгезләрдә үз чикләреннән тышта Норвегия күргән зиан турындагы мәсьәләгә кагылып, Кут, сугыш нәтиҗәсендә Норвегиянең 120 мең тоннадан күбрәк авырлыктагы 54 пароходын югалтканлыгын белдерде 392 моряк һәлак булган. Кут, Англия конвое астында Англия—Норвегия линиясе буенча бара торган „Мира" почта пароходына Германия самолетларының атуларына каршы протест белдерде.

Аннары Кут, пароходлар йөреше кагыйдәләрен бозуга каршы һәм Англия матбугаты фикеренчә, Англиянең „нейтралитетны техник бозуы"на каршы гүяки Норвегия протестлар белән чыгарга тиеш түгел дип раслаучы Англия газеталарына тукталды. Кут болай диде: „Англичаннарның „нейтралитетны техник бозу" дип әйткән нәрсәләре формаль мәсьәләләргә генә кагылмый. Аларның шулай ук гаять зур политик әһәмияте бар, чөнки мондый бозуларның ахыр чиктә шуңа китерүләре мөмкин ки, Норвегиянең территориаль сулары һәм, ихтимал, хәтта Норвегиянең территориясе дә сугышучы илләрнең сугыш кыры булып әверелүе һәм Норвегиянең зур сугышка тартылуы мөмкин. Шунлыктан Норвегия хокукны яклау белән генә калмый, бәлки үзен сугышка тартучыларга каршы үзен дә яклый. Нейтралитетны „зарарсыз" бозулар дип аталган нәрсә турындагы мәсьәлә безнең халкыбызның интересларына кагыла".

Төньяк илләренең „оборона союзы" турындагы мәсьәләгә күчеп, Кут, бу проблемада эшнең политик ягының әһәмияте аеруча зур икәнлекне әйтте. Мондый союз төзүгә СССР ның каршылык күрсәтүен искә алып, Кут болай диде: „Һәр хәлдә уйланылган союз турында нинди дә булса карар чыгарудан тукталып тору яхшырак. Финляндия өчен үзенең көнчыгыштагы куәтле күршесе белән ныклы тынычлык шартларында яшәү проблемасы чиктән тыш әһәмиятле мәсьәлә".

Аннары Кут болай дигән: Норвегия хөкүмәте, „оборона союзы" турындагы мәсьәлә буенча нинди дә булса җаваплылыкны, бу мәсьәлә стортингда тикшереп хәл ителмичә торып үзенә алырга уйламый.

Речөнең ахрында Кут, кечкенә нейтраль илләрнең принципта гына түгел, бәлки практикада да хәзерге сугыш барышында да, шулай ук сугыш беткәннән соң да милли бәйсезлеккә булган хокукларын сугышучы державаларның хөрмәтләүләрен таләп итүләрен белдерде.

В. И. УЛЬЯНОВ ЛЕНИН исемендәге Казан Дәүләт университетының
Математика һәм Механика Фәнни-Тикшеренү институты тарафыннан
12 һәм 18 нче апрельдә көндез 10 сәгатьтә
Дәүләт университетының актовый залында
урта мәктәпләрнең 9 һәм 10 нчы классларында һәм рабфак, шулай ук
техникумнарның югары курсларында укучыларның
МАТЕМАТИКА ОЛИМПИАДАСЫ ҮТКӘРЕЛӘ
Олимпиаданың беренче көнендә алгебра мәсьәләләре, ә икенче көнендә геометрия мәсьәләләр такдим ителәчәк.
Комиссия.
591—1

Район сәламәтлек саклау бүлекләре, колхоз правлениеләре һәм МТС лар игътибарына
РСФСР Наркомздравы Аптекалар Баш Идарәсенең Татарстан бүлеге алдагы чәчү кампаниясенә карата
КОЛХОЗ АПТЕЧКАЛАРЫ
ШУЛАЙ УК
ЯСЛЕ АПТЕЧКАЛАРЫ
хәзерләде һәм барлык район аптекаларына җибәрде.
Район аптекаларыннан колхоз һәм ясле аптечкалары бирелмәү хәлләре булса, түбәндәге адрес буенча, Аптекалар Баш Идарәсенең Татарстан бүлегенә мөрәҗәгать итәргә. Казан, Профсоюз урамы, 26.
522—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче апрельдә көндез һәм кич
ШӘМСЕКАМӘР
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 9 нчы апрельдә
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Иртәгә, 10 нчы апрельдә
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Бүген, 9 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ИРЕК
Иртәгә, 10 нчы апрельдә
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

25 нче апрель, кич 6 сәгатьтә Казан Дәүләт Ветеринария институтының патологик анатомия кафедрасы аудиториясендә, институтның өлкән лаборанты А. К. Малюков тарафыннан халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә
Тема: „Атларда аяк аралары уретростомиясе".
Рәсми оппонентлар: ветеринария фәннәре кандидаты доцент В. Г. Зайцев һәм ветеринария фәннәре кандидаты доцент Т. С. Минкин.
Диссертация материаллары белән институтның көтепханәсендә танышырга мөмкин.
588—1

Казан шәһәре Сталин районындагы 111 нче йорт идарәсенең югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга.
590—1

Ленин исемендәге Сукно фабрикасына (Казан, Киров районы, Гладилов урамы, 59) даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ, СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ һәм МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК ӨЧЕН КАРТОТЕКАЧЫ кирәк.
585—2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	КАТЕРИНА
КУЛЬТУРА САРАЕ	Кече залда, 5, 7 һәм 9 да ГРОЗА. Зур залда, кич 10 да ҖИР ПЛЕНДӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1366. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1293.